Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең
Улаклы Чишмә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
карары

03 декабрь 2022 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022 елның 03 декабрендә 10 сәгать 00 минутта узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлеге Улаклы Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: урам яктырткычларын норматив хәлгә китерү (материаллар сатып алу), смета төзү өчен түләү; су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү (материаллар сатып алу), смета төзү өчен түләү?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 33 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 25 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 20 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 5 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлегенең Улаклы Чишмә авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл җирлеге Улаклы Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару: урам яктырткычларын норматив хәлгә китерү (материаллар сатып алу), смета төзү өчен түләү; су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү (материаллар сатып алу), смета төзү өчен түләү?" турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Улаклы Чишмә авылы, Үзәк урамы, 32а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Васильевка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Васильевка авыл җирлеге башлыгы Ш.М. Касыймуллин